*Муниципаль тур*

**Татар телендә гомуми белем бирү оешмаларында укучы балалар өчен татар теленнән олимпиада биремнәренең ҖАВАПЛАРЫ**
**2025-2026 нчы уку елы**
**4 нче сыйныф**

**Максималь балл – 50**

## I. ТЕСТ (18 балл)

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| **4** | **3** | **2** | **1** | **2** | **3** | **1** | **1** | **1** |

## II. Теоретик бирем.

Шигырьне укыгыз. Берлек сандагы 1 һәм 2 зат алмашлыкларын тиешле килештә куеп, сүзләр белән языгыз. Зат алмашлыклары турында белгәннәрегезне языгыз. **(10 балл) 4+6**

**Синдә** җыр бар,
**Миндә** җыр бар –
Матур җырлар бик күп җирдә.
Синең җырың миңа күчсен,
**Минем** җырым **сиңа** күчсен –
Җырлыйк әле бергә-бергә (Ф. Яруллин).

Укучы мәктәп программасы, дәреслекләрдә бирелгән материалны мөмкин кадәр тулы чагылдырган очракта, биремгә иң югары балл **(6)** куела. Төгәлсезлекләрнең күләменә карап, баллар саны киметелә. Мәгълүмат бөтенләй булмаган очракта, укучыга 0 балл куела.

## III. Уйлагыз һәм җавапларны языгыз.

Фразеологик әйтелмә һәм аның мәгънәсен тәңгәлләштерегез, җавапны саннар белән языгыз. **(5 балл)**

| | |
|---|---|
| А) хәрәкәткә килү | 1) шәп белү |
| Ә) ут борчасы | 2) хәрәкәтчән |
| Б) су кебек эчү | 3) югалту |
| В) колак кагу | 4) ягымлы |
| Г) тәмле телле | 5) кузгалу |

**Җавап : 52134**

## IV. Гамәли-иҗади бирем.

1. Шигырьне укыгыз һәм күп нокталар урынына тиешле хәрефләрне куегыз. (**4 балл**)

М**е**нә ике көн инде
Үзем җыештырам өйне.
Буямагыз, белегез,
Бик сакланып **йөрегез**.

Җил чыкса, тузан керер,
Ф**о**рточканы ачмагыз.
Үзем җы**е**штырдым өйне,
Чисталыкны саклагыз!

(Заһирә Гомәрова)

2. Шигырьнең икенче куплетыннан басым соңгы иҗеккә төшмәгән сүзләрне күчереп языгыз (**2 балл**)

**ачмагыз, саклагыз**

3. *Җил* сүзенә 4 тамырдаш сүз уйлап языгыз. **(4 балл)**

җилле, җилсез, җилләү(ү), җиләс

4. “Чисталыкны саклыйк!” темасына 6-7 җөмләдән торган инша языгыз. **(7 балл)**